РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**Түбән Кама муниципаль районы**
**СОВЕТЫ**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 73** **2019 елның 7 ноябре**

Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә җәмәгать тыңлавы оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

10.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.2 Территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне межалау проектлары буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә җәмәгать тыңлавы үткәрү срогы, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып, иҗтимагый фикер алышу яисә җәмәгать тыңлавы нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр, бер айдан ким һәм өч айдан артык була алмый.»;

11.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.3 Җир кишәрлегенең яки капиталь төзелеш объектының шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәтләр бирү мәсьәләләре буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә җәмәгать тыңлавы үткәрү срогы, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр иткән көннән алып, иҗтимагый фикер алышу яисә җәмәгать тыңлавы нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр, бер айдан артык була алмый.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ НИЖНЕКАМСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

А.Р.Метшин